Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!

# Татарстан КОММУНИСТЫ

№7-8 (19-20). 2011 ел, 22 август. КПРФның Татарстан региональ бүлеге иҗтимагый-политик газетасы

Бу санда:
XIX парт-конференция,
сайлаулар,
‹БУЛГАРИЯ›,
ГКЧП
һ.б.лар

## Татарстан коммунистларының XIX партия конференциясе

23 июль көнне Казанда (провокаторларның бу чараны уздырмаска тырышуларына карамастан) КПРФ Татарстан региональ бүлегенең 19нчы чираттан тыш партия конференциясе булып узды.

Конференция эшендә РФ Дәүләт Думасы депутаты, КПРФ ҮК секретаре В.С. Шурчанов, Дәүләт Думасы депутаты, Армиягә теләктәшлек итү хәрәкәте председателе В.П. Комоедов, КПРФ ҮК оештыру бүлеге секторы мөдире В.Ю. Кузнецов катнаштылар.

2010 елның 3 августыннан 2011 елның 23 июленә кадәр башкарылган эшләр турында отчет һәм алда торган сайлауларга әзерлек уңаеннан республика партия оешмасы алдында торган бурычлар турында доклад белән конференция делегатлары каршында КПРФ Үзәк Комитеты члены, партиянең Татарстан региональ бүлеге республика комитеты беренче секретаре, ТР Дәүләт Советында КПРФ фракциясе җитәкчесе Х.Г. Миргалимов чыкты.

Конференциядә катнашучылар алдында шулай ук РФ Дәүләт Думасы депутаты В.П. Комоедов (КПРФ Үзәк Комитетының Татарстан Республикасы буенча кураторы) чыгыш ясады. Ул КПРФ фракциясенең Дәүләт Думасындагы эшчәнлеге турында сөйләде.

Конференция эше барышында республика коммунистлары КПРФның чираттан тыш узачак XIV съездына КПРФның Татарстан региональ бүлегеннән делегатлар сайлау өчен дә тавыш бирделәр. Съездга делегатлар итеп түбәндәге иптәшләр сайланды: Х.Г. Миргалимов, А.В. Прокофьев, Р.Ф. Нуретдинов.



*В. Шурчанов (сулда) һәм В. Комоедов конференциядә*

Конференция РФ Дәүләт Думасына депутатлар сайлауга КПРФның Татарстан региональ бүлеге рескомы тарафыннан тәкъдим ителәчәк кандидатлар исемлеген тикшереп, расладылар.

Моннан тыш, Татарстан коммунистлары вәкилләре КПРФның Татарстан региональ бүлеге җитәкчелегенең Россия Федерациясе Президенты постына КПРФ лидеры Г.А. Зюганов кандидатурасын күрсәтү турындагы тәкъдимен бертавыштан хупладылар.

Махсус оештырылган коткы (провокация) аркасында Татарстан региональ бүлегенең партия конференциясе билгеләнгән вакытыннан күпкә соң башлануны исәпкә алып, Конференция делегатлары булган вакыйгаларга тиешле бәясен биреп, партияне таркатырга маташучыларны КПРФ сафларыннан чыгару турында карар кабул иттеләр. Карар бүгенге газетада бирелә.

Чарада Татарстан Юстиция министрлыгы һәм Үзәк сайлау комиссиясе вәкилләре дә катнашты.

## КПРФ Татарстан региональ бүлегенең XIX чираттан тыш партия конференциясе КАРАРЫ

**«Түбәндәге затларны КПРФ сафларыннан чыгару турында: Гурьева Т.И., Максимов Н.Н., Фазлыева Н.С., Кормилицын А.Е., Ниязов Э.Ф., Вәлиев А.Р., Буторин А.В., Сальцин А.П., Иосипов Е.К., Сарсенбаев Е.Т., Ногманов Р.Н., Гарипов И.Р.»**

КПРФ Уставының 2.4, 2.11, 6.3 пунктларына ярашлы рәвештә конференция **КАРАР** бирә:

Түбәндәге затларны КПРФ сафларыннан чыгарырга:

1. Гурьева Татьяна Ивановна, КПРФның Чаллы шәһәр комитеты беренче секретаре.
2. Максимов Николай Николаевич, КПРФның Түбән Кама шәһәр комитеты беренче секретаре.
3. Фазлыева Неонилла Сергеевна, КПРФның Чаллы шәһәре Автозавод район комитеты беренче секретаре.
4. Кормилицын Алексей Егорович, КПРФның Чаллы шәһәре Комсомол район комитеты беренче секретаре.
5. Ниязов Эрнест Фәхретдинович, КПРФның Әгерҗе район комитеты беренче секретаре.
6. Вәлиев Альфред Рәкыйпович, КПРФның Казан шәһәре Авиатөзелеш район комитеты беренче секретаре.
7. Буторин Антон Валерьевич, КПРФның Казан шәһәре Идел буе район комитеты беренче секретаре.
8. Сальцин Александр Петрович, КПРФның Чистай район комитеты беренче секретаре.
9. Иосипов Евгений Константинович, КПРФның Казан шәһәре Авиатөзелеш район комитеты икенче секретаре.
10. Сарсенбаев Еркен Толешович, КПРФның Казан шәһәре Идел буе район комитеты члены.
11. Ногманов Рәшит Нәгыймуллович, КПРФның Түбән Кама шәһәр комитеты икенче секретаре.
12. Гарипов Илнур Рәшитович, ЛКСМның Татарстан Республикасы буенча элеккеге беренче секретаре.

**Казан шәһәре.**
**23.07.2011 ел.**

## Провокаторларның конференцияне өзәргә омтылышы барып чыкмады!

**Казандагы хәлләр турында «Интерфакс» корреспондентына КПРФ ҮК председателе урынбасары, Дәүләт Думасы депутаты В.И. Кашин һәм КПРФ ҮК оештыру-партия эшләре мәсьәләләре буенча секретаре, Дәүләт Думасы депутаты В.Ф. Рашкин аңлатма бирделәр.**

КПРФ җитәкчелеге 23 июльдә, шимбә көнне компартиянең Татарстан региональ бүлеге конференциясе узачак бина каршында провокация оештырган кешеләрне (хәзер инде компартиянең элеккеге членнарын) яхшы белүләре турында әйттеләр.

«Болар – башында Татарстан рескомының элеккеге секретарьлары торган биш-алты кеше – безгә күптәннән һәм яхшы таныш инде», – диде «Интерфакс» хәбәрчесенә КПРФ ҮК председателе урынбасары, Дәүләт Думасы депутаты В.И. Кашин.

Ул моннан җиде ел элек шушы ук «таркатучы-коткычылар»ның партия сафларыннан чыгарылганлыгын, әмма соңрак, кылган гамәлләренә үкенеп, КПРФ сафларында кабат торгызылган булуларын аңлатты. «Шулай булуга карамастан, – дип билгеләп үтте В.И. Кашин, – бу кешеләр партия дисциплинасын бозуларын дәвам иттеләр, партияне таркатуга юнәлдерелгән эш алып бардылар».

В.И. Кашин әлеге шимбә көнне дә бу төркемнең, тарафдарлары хуплавын тоеп, партиянең республика комитеты конференциясе узачак бинага үтеп керү юлына аркылы тәшәргә маташуларын искәртеп узды.

«Бу кешеләр бер генә максатны күздә тота – югалткан җитәкче постларны үзләренә кире кайтаруны һәм Дәүләт Думасы сайлауларына үз кандидатураларын исемлеккә кертүгә ирешүне», – диде ул.



Нәтиҗәдә, аның әйтүенчә, Татарстан партия конференциясе делегатлары ул шимбәдә, бу затларны КПРФ сафларыннан чыгаруны яклап, бердәм тавыш бирделәр.


«Күптән түгел алар безнең партия лидеры Г.А. Зюганов һәм башка җитәкчеләр белән очраштылар, без алар белән бик озак җентекле әңгәмә уздырдык, әмма бүгенге вакыйгалар күрсәткәнчә, бу кешеләр тәзәлү юлына басмаганнар, үзләренең таркату эшләрен дәвам иттергәннәр», – диде В.И. Кашин.

КПРФ Үзәк Комитетының оештыру-партия эшләре мәсьәләләре буенча секретаре, Дәүләт Думасы депутаты В.Ф. Рашкин, үз чиратында, «Интерфакс» агентлыгы журналистына биргән аңлатмасында таркатучы-коммунистларның партия сафларыннан нәкъ менә конференция делегатлары таләбе буенча чыгарылуын раслады.

«Алар конференциянең, КПРФның чираттагы съездына делегатлар сайлап һәм Дәүләт Думасына сайлауларда катнашу өчен Татарстаннан 34 кандидатның исемлеген раслап кына калмыйча, бүгеннән үк Татарстан рескомы җитәкчелеген дә кабат сайлап куюын таләп иттеләр, ягъни конференциянең форматын үзгәртергә уйладылар. Икенче төрле итеп әйткәндә, элек югалткан постларын кабат кайтарырга дигән ниятләрен, яшереп тормыйча, ачыктан-ачык диярлек белдерделәр», – дип аңлатты В.Ф. Рашкин.

Ул шулай ук, шушы ук биш-алты кешенең үзләренә тарафдарлар туплавын, конференция узачак торган бинага керү юлында пикет оештыруларын, коткы таратып гаугага куптаруларын, хәтта сугышуга барып җитүләрен, анда катнашучыларны полиция ярдәмендә араларга туры килүен дә әйтеп узды.

*Россия, хезмәт, халык власте, социализм!*
**РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ КОММУНИСТЛАР ПАРТИЯСЕ**



## Халык референдумы — Әйе
## 30 сентябрьдә тәмамлана — Әйе

КПРФ Үзәк Комитеты игълан иткән «Халык референдумы» уңышлы төстә ахырына якынлаша. Бу турыда партия оешмаларыннан куанычлы хәбәрләр килә. Узган 7 ай эчендә Татарстан буенча 80 меңнән артык имза җыелды. Аеруча Буа (И. Садриев), Яшел Үзән (В. Мурахов), Чистай (Ю. Петров) шәһәрләре партия активистлары яхшы эшләде. Ә менә Казан, Чаллы, Түбән Кама, Зәй шәһәрләрендә сүлпәнлек сизелә. Сентябрь аенда аларга активлашу сорала.

## Ульяновскида ЛКСМ слёты

13 августта В.И. Ленинның туган җире Ульяновскида Идел буе федераль округының беренче кеңгә исәпләнгән комсомол активы слёты эшли башлады. Яшьләр форумына Мари Эл, Мордовия, Татарстан, Удмуртия, Чувашия республикаларыннан, Пермь крае, Киров, Оренбург, Пенза, Самара, Саратов һәм Ульяновск өлкәләреннән 100дән артык булып яшьләр килде. Татарстан ЛКСМ делегациясе составында КПРФның яшьләр эше буенча республика комитеты секретаре Р.Гайфуллов, комсомол активистлары Э.Мадиров, А.Комиссаров, А.Әхмәтшиннар бар иде.

## Татарстан Госсоветы депутаты Хафиз МИРГАЛИМОВ:

*– Халыкның 62 проценты СССРның таркалуына үкенә. Дөньядагы барлык фаҗигаләр, Африкада, Европада, Америкада булмасын, СССР таркалуга бәйле. Чөнки дөньяда баланс бетте. Әгәр ул юк икән, табигатьтә дә, җәмгыятьтә дә, хәтта галәмдә дә катаклизмнар башлана. Вакыт узган саен, СССРның киреклегенә һәм аның килечәктә кабат барлыкка киләчәгенә иманым камил. Путч ярдәмендә илне саклап калырга тырыштылар. Әмма булдыра алмадылар. Ә бүген андый хәлләр килеп чыкса, аларга ияреп урамга чыгар идем. Ул заманда да кешеләр бүген ничек яшәвебезне белсә, илне саклап калу өчен активрак көрәшкән булыр иде.*

### Түбән Новгородта халык җыены

## «Халык ополчениесе» төзелде




Әлеге карар КПРФ тарафыннан 1,5 мең кеше катнашында Россиянең 30 регионыннан килгән вәкилләр тарафыннан 16 июль көнне Түбән Новгородта үткән чарада кабул ителде. Биредә Казан, Чаллы, Яшел Үзән, Бөгелмә, Алабуга һ.б. шәһәрләрдән милли киемнәрдә килгән делегация дә булды. Татарстан вәкилләре палаткасы алдында рус һәм татар җыр-биюләре, гармун тавышы тынып тормады. Безнең делегацияне Татарстан Госсоветы депутатлары Х.Г. Миргалимов, Р.Ф. Нуретдинов һәм А.В. Прокофьев җитәкләделәр.

«Юпитер» концерт залында үткән конференциядә катнашучылар Г.А. Зюганов кандидатурасын президент постына тәкъдим итүне бердәм рәвештә хупладылар. Аннан Геннадий Андреевич үзе сүз алды. Анардан соң РФ Госдумасы депутатлары, җәмәгатьчелек вәкилләре чыгыш ясадылар.

Халык җыенына килүчеләр концерт залыннан кызыл флаглар һәм транспарантлар тотып, тынлы оркестр музыкасы астында Кремльгә, аннан Халык бердәмлеге мәйданына юнәлделәр. Анда Минин һәм Пожарский һәйкәленә чәчәкләр салынды, митинг үтте. Шествиедә катнашучылар саны 5 меңгә җитте.

**Илшат ВӘЛИУЛЛИН,** Казанның Киров райкомы I секретаре.

## ГКЧПга – 20 ел

***СССРның таркалуына китергән ГКЧП фетнәсенә 19нчы августта 20 ел тулды. Илнең ул вакыттагы югары дәрәҗәдәге түрәләре, ил башлыгы Горбачевны вазыйфасыннан читләштереп, илдә гадәттән тыш хәл керттә. Фетнәне яклап, сөенеп кабул итеп, аннан вәзгыять алышынгач, киресенчә, коммунистлар фиркасе партбилетын утка атып, коммунистларны бетерү өчен җан-фәрман чапкан адәмнәрнең күбесе әле бүген дә – зур түрә.***

## Ринат Мөхәммәдиев:
# «ГКЧП БУЛАСЫН ИКЕ АТНА АЛДАН БЕЛДЕК»

**Бүген Мәскәүдә гомер итүче әдип 1989-1999 елларда Татарстан язучылар берлеген җитәкләде, 1990-1993 елларда – Русия Югары Советы, 1995-1999 елларда Татарстан Дәүләт Советы депутаты булып торды. Әдип «Азатлык» радиосы сорауларына җавап бирде.**

*– 1991 елның август фетнәсе, ГКЧП. Советлар Берлеге язмышын хәл иткән сәяси борылышка быел 20 ел. 18-21 август көннәрендә Советлар Берлегенең үзәк комитеты вәкилләре, хөкүмәт җитәкчеләре яңа берлек килешүенә кул куйдырмау, илне кире авторитар хакимияткә кайтару өчен ГКЧП төзеп, фетнә-путч китерел чыгара. ГКЧП турында кайда ишеттегез?*

– ГКЧП Русия парламенты җәйге ялларга таралгач оештырылды. Ләкин депутатлар бу турыда алдан кисәтелде. Фетнә чыгасы турында 20 көн алдан белә идек. Бу көтелмәгән вакыйга булмады. ГКЧП сценаристлары белән хакимияттә утырган кешеләрнең үзара сөйләшүләре булган. Фетнә турында Кырымдагы татарлар башлыгы Мостафа Җәмилев өеңдә ишеттем. ГКЧПның максаты – элекке системаны саклап калу, дип уйлыйлар. Ләкин минем фикеремчә, фетнә кайбер көчләрнең кискен революция ясар өчен оештырылган коткысы булды. Әгәр шул вакытта ГКЧП оешмаса, турыдан-туры СССРны таркатып, КПСС хакимиятен бетереп булмый иде. Путч китереп чыгаруда СССРны бетерергә теләгән демократ көчләр һәм чит ил кешеләре катнашты.

*– ГКЧП турында СССР президенты Михаил Горбачев алдан белдеме? Монда Борис Ельцинның катнашы бармы?*

– Мин алар белән ныклап аралашкан кеше. Ельцин белән ерак сәфәрләрдә дә булдым. Аларның үзара килешеп куюы бик ихтимал. Горбачевның ул вакытта ил җитәкчесе буларак көче бар иде. Аны дачада яшереп яткырдылар дигән сүз – әкият! Чөнки шул көнне мин Гаградан Бакчасарай шәһәренә машинада үттем. Анда бернинди сак юк иде. ГКЧП, беренче чиратта, хакимиятне кулга алырга теләгән, илне таркатырга теләгән Борис Ельцинга кирәк иде.

*– ГКЧП көннәрендә Мәскәү урамына танклар керә, кан коеш башлана…*

– Бернинди дә кан коеш булмады. Бу кечкенә генә бер тамаша. Анда өч-дүрт малайның танк астына керүе очраклы хәл. Һәрхәлдә фетнә көннәрендә кан коеш булды, дип әйтеп булмый. Бер танкист та кеше таптарга боерык алмаган. 1993 елда парламентны бомбага тоту белән чагыштырганда, 1991 елда үтерешкә омтылыш бар, иде дип әйтә алмыйм.

**С. ДОЛГОВ.** («Азатлык» радиосы).

*Татарстандагы кода-кодагыйлык, халык милкен урлау, аны акрын гына үзләштерә башлау, табигый байлыкларның халыкныкы икәнен онытып, аны бер төркем кешеләрнең милкенә әйләндерү күренешләре белән кискен риза түгел идем.*

*Һәрхәлдә ришвәтчелек, дәүләт милкен булү, талау башлана икән, аны тиз генә туктатып булмый. Ул канун чыгарып, ниндидер җитәкченең әмере белән генә туктала торган күренеш түгел. Кызганыч, Татарстан белән Русия ришвәтчелек ягыннан Африкадагы иң ришвәтчел илләр белән бер рәттә.*

(Р. Мөхәммәдиевның, «Азатлык» радиосына интервьюсыннан).

## Коммунистлар пикеты өчен
## музыка мәктәбе директорына штраф яный

Аңа карата прокуратура административ хокук бозу турында эш кузгатты. Агымдагы елның 23 июле көнне Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан Дәүләт консерваториясе каршындагы музыка мәктәбе бинасы янында коммунистлар тарафыннан оештырылган тәртипсезлекләр өчен шул мәктәпнең директоры җавап тотачак.

Казан шәһәренең Вахитов районы прокуратурасы Александр Михайловка карата РФ Административ хокук бозулар кодексының 7.24нче статьясының 1нче өлеше буенча («Федераль милек булып саналган торак булмаган фонд объектын башкарма власть федераль органы уполномоченныеның махсус рөхсәтеннән башка файдаланган өчен») административ эш кузгатты.

Район прокуратурасыннан алынган мәгълүматларга караганда, мәгариф учреждениесе директоры, үткәрелә торган чараның максатларына ныклап төшенми торып, мәктәп бинасындагы бүлмәне, аренда килешүе төзеп тормастан, яисә дәүләт органы («Росимущество» федераль хезмәте Татарстан идарәсенең) рөхсәтеннән башка гына, аерым затлар карамагына биреп торган.

Михайловның бу ваемсызлыгыннан файдаланып, КПРФ политик партиясе вәкилләре мәктәпнең актлар залында КПРФ Татарстан региональ бүлегенең конференциясен уздыралар.

Шул ук вакытта «Мәгариф турында»гы РФ Законының 1нче статьясының 5нче пункты нигезендә мәгариф оешмаларында политик партияләр эшчәнлеге алып бару тыела.

Мәктәп бинасы янында стихияле төстә пикет оешып китә, КПРФ лидерлары тарафдарлары һәм аларның каршы яклары арасында ачыктан-ачык каршылык чыга. Музыка мәктәбенә керә торган басмыч төбендә оештырылган пикетта, прокуратура мәгълүматларына караганда, 100дән артык кеше катнаша, 20дән артык полиция хезмәткәренең катнашып китүе кирәк булып чыга.

КПРФның ТР Рескомы җитәкчесе Хафиз Миргалимовка район прокуроры тарафыннан «Мәгариф турында»гы Законны бозуга юл кую факты, дәүләт милкеннән файдалану регламентлары тәртибен бозган өчен шулай ук күрсәтмә бирелде.

Район прокуратурасы шулай ук, гамәлдәге законнарны бозу очракларын бетерүне таләп итеп, Казан шәһәре Эчке эшләр идарәсе начальнигы Рөстәм Кадыйров исеменә дә күрсәтмә юллады. Низаг (конфликт) урынына килгән полиция хезмәткәрләре мәгариф оешмасы хезмәткәрләренең һәм шулай ук КПРФның Татарстан региональ бүлеге әгъзаларының гамәлләре законлымы-юкмы икәнлеген ачыклап тормастан, хәлгә катнашып китеп, административ хокук бозу җәһәтеннән вакыйгаларны җайга салу урынына, киресенчә, аларның куерып китүенә булышлык кына иткәннәр.

«Татар-информ» агентлыгы корреспондентына район прокуратурасында ачыклап әйтүләренчә, Михайловтан 5 мең сумга кадәр штраф түләтү каралган.

**(«Татар-Информ» агентлыгы, 04.08.2011 ел).**

**Редакциядән.** Музыка мәктәбе директоры бүгенге көндә чираттагы ялда. Коммунистлар белән «дус» булган өчен генә аны эзәрлекләү гаделсезлек булыр иде, директорның язмышы белән кызыксынып торачакбыз, бу турыда Культура министрлыгы җитәкчелеге белән дә сөйләшеп торам, диде ТР Госсоветының КПРФ фракциясе җитәкчесе Х.Г. Миргалимов.

## Яңа китап: «Үз кешеләр»



Мәскәүнең «Голос-Пресс» нәшриятында 3 мең тираж белән басылган әлеге китапның авторы күренекле татар язучысы, филология фәннәре кандидаты, Г. Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт премиясе лауреаты, Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре Ринат Мөхәммәдиев. Ул укучыларга катлаулы тарихи вакыйгаларга багышланган романнары, заман укучысының җанын телгәләгән проблемаларны фаш иткән повестьлары һәм нечкә лирик хисләрдә өртелгән кыю һәм актуаль хикәяләре белән яхшы таныш. Әлеге китапта автор иҗатының төрле чорларында язылып, укучылар тарафыннан яратып кабул ителгән сайланма хикәя һәм повестьларын тәкъдим итә.

Китапка «Якутлар табыладыр вакыт белән» дип исемләнгән кереш сүзне филология фәннәре докторы, профессор Фоат Галимуллин язган.

Ринат Мөхәммәдиев «Кенәри читлек кошы», «Сират күпере», «Утлы таба өстендә», «Алланың кашка тәкәсе», «Кош булып очар идем» романнары, «Беренче умырзая», «Ак кыялар турында хыял», «Истәлек өчен Гыйлемханга» повестьлары авторы. Ул Азия-Африка илләренең «Лотос», Россиянең М.А. Шолохов исемендәге һәм Төркиянең халыкара премияләре лауреаты.

Яңа китап сатуга чыкты, белешмәләр өчен телефон: **89600623230.**

## КАРАК
### (хикәядән өзек)

Туып алган тынлыктан файдаланып, байтак гомерләр дәшми генә утырган министр сүз башлады шунда.

– Якын арада шәһәрнең берничә заводын аукционнан сатарга җыенабыз. Артык расходланмый гына шуларны үз кулыбызга төшерү кулай булачак. Фикерләрегезне тупләп торыгыз.

– Фикерләр бар, бушка булса мин баш тартмаячакмын, – диде депутат.

– Сатылачак заводлар исемлеген иң беренче миңа күрсәтергә онытма, – дип, генерал да кызыксынуын белдерергә онытмады.

Ә банкир исә, аңлашты дигән мәгънә белгертеп, министрга күз кысып кына куйды.

– Хакимият үз кулыбызда, без инде үз-үзебездән акча чыгармау җаен гына табарбыз. Тик бер шарт булачак. Бу эш үз исемегездән түгел, балаларыгыз, кияүләрегез исеменнән башкарылганда кулай булачак. Югарыдагы абзыйның шарты шундый...

– Ул кадәресе әйбәт түгел икән, – дип, уйга калды, шәрәләнә башлаган баш түбәсен кашып алды депутат. – Минем кыз белән кияү, үзең беләсең, Америкада. Алар әлегә кайта алмаска мөмкин, тиздән гражданлык алырга тиешләр иде. Үзләреннән башка гына хәл итеп булырмы икән?

– Бик тырышсак булыр, ник булмасын...

– Юктан проблема чыгарып маташмагыз инде, – дип, бу сөйләшүләргә әллә ни исе китмәгәнлеген аңлатып бер читкә «тач» итеп төкереп куйды шулчак генерал. – Синекеләр генә түгел, беребезнең дә балалары монда кәҗә көтүе көтеп ятмый инде, кайсы кайда чит илдә укыйлар, һәм шунда калалар да...

– Әхәт Сабирович дөрес сөйли, юк белән башны катырмыйк. Имзалары булса тагы ни кирәк, бик җиткән, – дип, мәсьәләне йомгаклап та куйды министр. – Заводларның исемлеген мин киләсе атнада җиткерермен үзегезгә.

– Бүген үк булмыймы?

– Ашыкмыйк. Иң элек, анда, югарыдагы абзыйларга һәм аларның малайларына ни кирәген ачыкларга кирәк, – дип, бармагын югарыга текәде министр. – Алардан калганы безнеке, борчылмагыз. Заводларыгыз да булыр, яхталар, кирәксә самолетларыгыз да...

– Ә ул заводларда эшләгән ач халыкны соңыннан безнең өскә таып куймаслармы соң? – дип, халык язмышын кайгыртудан түгел, үз кесәсен истә тотып сорау бирде депутат.

– Тапкансың борчылырга сәбәп, – дип, фикерен тәмамларга да бирмәделәр аңарга. Милиция генералы кистереп кенә куйды.

– Ул депутат кеше, дөрес эшли – халыкны кайгырта. Аның вазифасы шундый, – дип сүз кыстырды министр, әшнәсен аңлап бетермичәрәк.

– «Халык депутаты» дигән төшенчә юк хәзер, колагыгызга киртләп куегыз, аларны «депутат» кына диләр. Очраклы рәвештә дип уйлыйсызмы? Юк, бер нәрсә дә очраклы булмый!!! Депутатны халык сайламый, хакимият башында утыручы билгели бүген. Шуңа да ул, иң элек, үзенә дәрәҗә бирүчегә баш ия. Һәм шуннан соң гына үзен кайгыртырга керешә. Ә халык нәрсә ул!.. – дип, чираттагы мәртәбә борынын җыерып бер читкә төкереп куйды генерал. – «Халык» дигән төшенчә генә калды, ә чынлыкта халык юк инде ул. Халык ни дә, сарык көтүе ни, аермасы калмады.

# ХАЛЫК НИК САЙЛАУЛАРГА ЙӨРМИ,

## яки сайлаулар демократия институтымы, әллә чираттагы тамашамы?

**Участок сайлау комиссиясе председателе мандаты закон бозучыны, әгәр ул власть партиясе вәкиле икән, җавап бирүдән ышанычлы саклый. Ә башка партияләр вәкилләренең хәле ничегрәк? Закон каршында барлык партияләр дә бердәй тигезме? Демократияне, әгәр ул безнең җәмгыятьтә чыннан да кирәк дип саныйбыз икән, камилләштерү өчен «Политик партияләр турында»гы Законны кабат карарга вакыт җитмәдеме икән?**

Россиядә чираттагы Президент сайлаулары якынлаша, әмма илдә әле узган сайлаулар шаукымының да тынганы юк. Әйтик, Азнакайда соңгы тапкыр РФ Президентын сайлау вакытында, 2008 елның 2 мартында, КПРФ тарафдары Тимергали Усманов 508нче номерлы сайлау участогында оппозиция партиясеннән күзәтүче булып катнашкан иде. Партиядәше, хәлиткеч тавышка ия булган сайлау комиссиясе члены Җәүдәт Ситдыйков белән берлектә, алар бик тупас тайпылышны ачыклыйлар. Мондый гамәл алар өчен шактый кыйммәткә төшә: Т. Усмановның башта үзенә яныйлар, аннары 30 ел намус белән хезмәт иткән системадан – «Водоканалсервис»тан чыгарып ук ташлыйлар. Оппозиция тарафдарлары туктап калмый, Генпрокуратурага кадәр барып җитеп, җинаять эше кузгаттыруга ирешәләр.

Нәтиҗәдә, 2008 елның 2 октябрендә Азнакай районы килештерү (мировой) суды 508нче номерлы сайлау участогы председателе урынбасары Илгизә Сираеваны РФ Җинаять Кодексының 142нче статьясы, 2нче өлеше (сайлаучылар имзаларын ясау) буенча гаепләү турында хөкем карары чыгарды. Бу карарда Татарстанда сайлаучылар ихтыярына бәйле нәтиҗәләрне ничек бозып күрсәтүләре белән бәйле кара эшләр чиста су тамчысындагы кебек ачык чагыла. Әйтик, суд карарында И. Сираеваның, РФ Президентын сайлаулар вакытында Азнакай шәһәрендәге 508нче номерлы сайлау участогы сайлау комиссиясе председателе урынбасары буларак, сайлаучыларның сайлауга килүләре һәм шулай ук тавыш бирүләре турындагы мәгълүматларны бозып күрсәтү максаты белән сайлаучыларның исемлеге языласы 3нче номерлы китапка шундый-шундый сайлаучылар тарафыннан (барлыгы 19 кешенең фамилиясе күрсәтелгән) тавыш бирү өчен сайлау бюллетеньнәре алыну турында алдан ук дөрес булмаган мәгълүматлар язуы, әлеге затларның имзалары ясап куелуы һәм паспортларының номерлары күрсәтелүе турында әйтелә. Моннан соң И. Сираева, РФ Президентын сайлау вакытында тавыш бирү нәтиҗәләрен бозып күрсәтү дигән мәкерле ниятен гамәлгә ашыруны дәвам итеп, тавыш бирергә килмәгән югарыда күрсәтелгән кешеләр өчен сайлау бюллетеньнәре алып, алар исеменнән үзе сайлаган да.

Кызыгы шул, судта Сираева каршы килеп тә маташмый (беренче тапкыр гына түгел, күрәмсең), ул үз гаебен тулысынча таный һәм эшне тизрәк, ягъни аерым тәртиптә карауларын үтенә. Җәза чарасын билгеләгән чакта суд аның үз гаебен тануын, яшәү һәм эшләү урыннарыннан уңай характеристика бирелүен, ә иң мөһиме, аның «2002 елда халык санын алуда актив катнашкан өчен» Россия Госкомстатының күкрәк билгесе һәм 2006 елда Бөтенроссия авыл хуҗалыгы җанисәбен алуда актив катнашкан өчен медаль белән бүләкләнгән булуын исәпкә ала. Шик юк, Сираева ханым халык санын алуны да сайлауда эшләгән кебек тайпылышлар белән уздырган булырга тиеш һәм җитәкчеләргә кулай булган мәгълүматларны ясау аңа авыр булмагандыр.

Ничек кенә булмасын, бюллетеньнәрне әвеш-тәвеш китерүче бу ханым, кем әйтмешли, судан коры чыкты дияргә була – суд аннан нибары 7 мең сум штраф түләтү турында карар чыгарды. Хөкем ителүченең хәтта эш урынында да бернинди каршылык тумады – пенсия яшендә булуга карамастан, тәзекләндерү һәм яшелләндерү эшләре белән шөгыльләнә торган, очы-кырыена барып чыкмаслык исемле бер оешмада (ООО «МППБ и О» дип атала ул) ярыйсы ук җылы һәм чиста урында инженер булып шактый озак утырды әле ул.

Ә менә тынычлыкны бозган Тимергали Усманов турында һич алай дип әйтеп булмый. Инде шул сайлау көнне үк «Водоканалсервис» ААҖ филиалы «Азнакай җылылык челтәре предприятиесе» директоры Т. Усмановны урамга чакырып чыгарып, эштән чыгару белән янап, бик каты сүзләр белән, кичекмәстән сайлау участогын ташлап китүен таләп иткән. Бу факт Азнакай шәһәре прокуроры Ф. Сәлимовның (хәзер ул Мөслим районы прокуроры) 2008 елның 24 апрелендәге №99ж-08 номерлы җавабында беркетелгән. Шул ук җавапта «янауларның хәзерге көнгә кадәр туктаганы юк» икәнлеге турында да әйтелә.

Шунысы игътибарга лаек, Тимергали Усмановны туган «Водоканалсервис»ыннан куу турында янаулары, сүздә генә калдырмыйча, тормышта чынга да ашыралар. Ул үзен кабат эшкә кайтаруларын сорап, судка мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була. Властьтагылар өчен гаять «җайсыз» булган бу дәгъваны, билгеле инде, судта мөмкин кадәр озаграк тоткарлап, хөкем карарын бары тик 2010 елның 1 октябрендә генә чыгаралар. Алдан ук сизенүләр дөрескә чыга һәм аны эшкә кайтарудан баш тарталар. Әмма бу карар белән ТР Югары судында килешмиләр һәм 2010 елның 2 декабрендә, Азнакай шәһәр суды карарында күп кенә хилафлыклар табып, әлеге эшне кабат карауга җибәрәләр.

Анысы 2011 елның 20 гыйнварында була. Бу юлы Усманов җиңеп чыга: Азнакай шәһәр суды аны транспорт участогы начальнигы вазыйфасында торгызу һәм «Водоканалсервис» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы – Азнакай җылылык челтәре предприятиесеннән Усмановка эшсез йөрергә мәҗбүр булган вакыты өчен тиешле хезмәт хакын – 107 421,95 сум акча түләтү турында карар чыгарды.

2011 елның 21 мартында ТР Югары Суды әлеге карарны үзгәрешсез калдырды. Шулай булуга карамастан, баштан ук фаразланганча, Усманов элекке эш урынында алга таба эшли алмады, аны түзеп булмаслык шартларга китереп куйдылар һәм ул үз теләге белән эштән китәргә мәҗбүр булды.

Тимергали Усмановның башка көрәштәшләренең дә принципиальлекләре үзләренә кырын суга: дөреслек өчен көрәш юлында Җәүдәт Ситдыйковны инсульт китереп бәрдә һәм ул беренче группа инвалид булып калды. Ә мине, РФ Президентлыгына кандидат Г. Зюгановның ышанычлысын, үзем җитәкләгән учреждениене ликвидацияләү юлы белән эшсез калдырдылар.

Миңа, беренче группа инвалид улымны тәрбияләүче гаилә башлыгы булсам да, ел ярым дәвамында Азнакай шәһәренең эш белән тәэмин итү һәм мәшгульлек үзәгендә исәптә торырга туры килде. Шуннан соң, РФ Журналистлар союзы члены һәм Татарстанның «Алтын йөрәкле журналист» Дипломы белән бүләкләнгән булуымны искә алып, ТР Дәүләт Советының КПРФ фракциясендә «Татарстан коммунисты» республика газетасының баш редакторы урынын тәкъдим иттеләр, мин риза булдым. Шулай итеп, властьтагылар мине профессиональ җирлектә оппозиция эшчәнлеге алып барырга мәҗбүр иттеләр.

Ә бит шул ук вакытта, Азнакайда законнар үтәлешендәге башбаштаклыкларга каршы көрәшүчеләр шундый кыен хәлдә калганда, закон бозучылар үзләрен гаять иркен хис итеп яшиләр. Ни өчен? Шуның өчен, чөнки безнең законнар шундый итеп кабул ителгән ки, алар еш кына җинаятьченең үзен яклауга корылган. Моңа ачык мисал – Азнакай шәһәре прокурорының 2011 елның 7 июнендә җитәкче кеше тарафыннан закон бозу фактына карата биргән №176ж-11 санлы җавабы. Башта әлеге мөрәҗәгать 2011 елның 13 маенда Азнакайда гражданнарны кабул иткән көнне Татарстан Республикасы прокурорына адресланган иде. Мөрәҗәгать дигәнебез Азнакай җылылык челтәре предприятиесенең торбаларны сүтү эше белән «тәэмин иткән» өчен 2007 елның 4 декабрендә бер эшмәкәрдән законсыз төстә 76,5 мең сум акча алган бер җитәкчесенә һәм баш инженерына карата прокуратура инициативасы белән җинаять эше кузгату мөмкинлеген аңлатуны сорап язган үтенеч иде ул.

Татарстан прокуроры әлеге эшне Азнакай прокурорына йөкли. Анысы исә мондый җавап язган: «Тикшерү барышында 2007 елның 4 декабрендә Азнакай эчке эшләр бүлегенең тикшерү изоляторында «Водоканалсервис» ААҖ филиалы Азнакай җылылык челтәре предприятиесе директоры урынбасары И.А. Шиһапов белән шул ук предприятиенең баш инженеры И.Я. Галиевнын, әлеге предприятие участогында җылылык челтәре торбаларын сүтәргә мөмкинлек биргән өчен дип, бүләк рәвешендә М.К. Хәлиуллин белән Д.Ф. Сәетгәрәевтан 25 000 сум акча алу факты буенча РФ Җинаять кодексының 204нче статьясы, 4нче өлеше, «а» пунктында каралган җинаять билгеләре буенча №471945нче санлы җинаять эше кузгатылган булуы ачыкланды».

Бер карауга, барысы да ачык аңлашыла кебек. Әмма шуннан соң прокурор Шиһаповка карата җинаять эшенең законсыз төстә кузгатылганлыгы, чөнки аның 522нче сайлау участогында сайлау комиссиясе председателе булып торганлыгы турында яза, җинаять-процессуаль законнарда андыйларга карата җинаять эше алып баруның аерым тәртибе каралганлыгын әйтә: «Күрсәтелгән категория затларга карата җинаять эше, 2007 елның декабрена булган торыштан чыгып, бары тик РФ субъекты прокуроры тарафыннан гына кузгатыла ала» – Азнакай шәһәре прокурорының җавабы әнә шундый.

Эш нәрсәдә соң, дигән сорау туа. Мөрәҗәгать ТР прокурорына адресланган иде ләбаса, ни өчен соң ул участок сайлау комиссиясе председателе мандатын йөрткән ришвәтчегә карата җинаять эше кузгатмаган? Ни өчен аңа шул таныклыгы артына яшеренергә ирек биргән? Эшнең асылына карап, төпле карар кабул итәсе урында, ни өчен ришвәтченең эшен Казаннан кабат Азнакайга кайтарып, анда иплән кенә йомып куйганнар? Менә шуннан чыга инде ул сайлаулар вакытында мөһим вазыйфаларны башкару өчен криминал белән бәйле кешеләрне билгеләп кую. Берәү имзалар ясап тотылган, икенчесе ришвәтчелектә фаш ителгән... Сайлау процессындагы дөреслекне-сафлыкны шундый шикле затлар сакларга алына икән, сайлау турындагы законнарның дөрес үтәлеше, гаделлек турында нинди сүз йөртергә мөмкин соң? Бер сүз белән әйткәндә, РФ Дәүләт Думасына депутатлар һәм РФ Президентын чираттагы сайлаулар якынлашканда сайлаучыларга һәм хокук саклау органнарындагыларга уйланыр нәрсәләр күп...

**Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ,**
**Россия журналистлар союзы члены.**

# Россия: башкаларны куып җитеп, узып киткән «казанышлар»

**Россия генераллар саны белән – беренче, миллиардерлары белән – икенче, гади кешеләрнең иминлеге күрсәткече белән – дөньяда 175нче урында.**

**Әлеге исемлек дөньякүләм үткәрелгән төрле халыкара рейтинглар нигезендә эшләнде.**

**РОССИЯНЕҢ «БЕРЕНЧЕ УРЫННАРЫ»:**

– Россиядә яшәүчеләр соңгы сигез ел эчендә 2,2 миллионга кимегән. Үлүчеләр саны белән Россия, Украинадан соң, икенче урында. Илдә елына 800 мең кеше үлә.

– Үз-үзләрен үтергән балалар һәм үсмерләр саны буенча Россия Европа илләре арасында беренче урында. Үз-үзләренә кул салучылар буенча Россия, дөньяда Литва, Көньяк Корея, Казахстан, Белорус һәм Япониядән соң, алтынчы урында.

– Аерылышучылар.

– Ата-аналары баш тарткан балалар.

– Йөрәк һәм кан әйләнеше авыруларыннан үлүчеләр.

– Россиядә 2,5 миллион кешедә яман шеш авыруы бар.

– Кеше белән сәүдә итү.

– Россиядә һәр сәгать саен ана карынындагы 300 бала юк ителә. Кушма Штатлар белән чагыштырганда сигез тапкыр күбрәк.

– Дөньяда җитештерелгән барлык героинның 21%ы Россиядә кулланыла. Әфьюнлы матдә булган наркотикларның 5%ы Россиядә кулланыла.

– Тартучы балалар.

– Читтән машина кертү. Россия шулай ук куллану вакыты чыккан иң күп чит ил машиналары йөргән ил дә булып тора.

– Табигый газ табу һәм аны читкә сату. Дөньяда табылган бөтен газның 35%ы Россиядә чыга.

– Урманнар күләме. Дөньядагы бөтен урманнарның 23%ы – Россиядә.

– Узган ел Россиядә 500 миллион тонна нефть табылган. Аны читкә сату буенча Россия – дөньяда икенче урында.

– Россиядәге бар халыкның 39,1%ы тәмәке тарта. Икенче урындагы Кытайда бу күрсәткеч 26%. Өченче урындагы АКШта бар халыкның 16%ы гына тәмәке тарта.

– Рәсми мәгълүматларга караганда, 2009 елда педофилләр 124 мең тапкыр балаларга һөҗүм иткән. Россиядә бар җенси җинаятьләрнең яртысы балаларга карата кылына.

– 11 яшьтән 18 яшькә кадәр булган Россиялеләр исерткеч эчемлекләрне даими куллана.

– Илдә 760 мең ятим бала һәм миллионга якын кечкенә сукбай бар.

– Узган ел Европада кеше хокуклары судына 40295 шикаять җибәрелгән. Икенче урында Төркия (15206), өченче урында Румыния (11950) тора.

– Генераллар саны белән.

**РОССИЯНЕҢ «ИКЕНЧЕ УРЫННАРЫ»:**

– Ялган (контрафакт) товар җитештерү. Беренчелек – Кытайда.

– Бюрократия иң нык үскән ил – Бразилия. Россиядән соң, өченче урында – Польша. Эшмәкәрләр фикеренә караганда, Испания, Сингапур һәм Швеция бизнес үсеше өчен иң кулай илләр булып тора.

– Долларлы миллиардерлар. Беренчелек америкалыларда.

– Интернетка таралган балалар порнографиясе. Беренчелек – АКШта.

– Төрмәләрдә утыручылар саны. Россиядә 100 мең кешедән 584е ябылган. АКШ беренче урында, Кытайга – өченче урын.

– Россиягә елына 10-12 миллион мигрант килә. Беренче урындагы Кушма Штатларга елына 42,8 миллион мигрант килә. Бу күрсәткечләрдә Россиядән соң Германия, Согуд Гарәбстаны, Канада һәм Франция тора.

– Ялган дару. Кытай беренче урында. Россиядән соң Төркия, Бразилия һәм Чили килә.

– Корал сату. Күп еллар инде бу өлкәдә Кушма Штатлар беренчелекне беркемгә дә бирми. Британия – өченче, Франция – дүртенче урында.

**РОССИЯНЕҢ «ӨЧЕНЧЕ УРЫННАРЫ»:**

– Елына 2,6 миллиард долларлык пират дискы сатыла.

– Россиядә елына 119 мең машина урлана. Интерпол мәгълүматлары буенча, Италия машина иң күп урланган ил булып тора. Анда елына 300 мең машина урлана. Икенче урында торган Германиядә 140 мең машина урлана.

**Наил АЛАН.**

# ЛЕНИН БАБАЙНЫ ОНЫТМЫЙК!



Пролетар юлбашчы В.Ленинны бүген искә алган кеше юк. Мин үзем галстук бәйләп, аның значогын түшемә кадап, укыдым. Ул бит – крестьяннарга җир, ирек бирүче революционер. Аны элеккеге буын кешеләре онытмый, ә хәзергеләр искә дә алмый.

Мавзолейдан алып, күмәргә, дип, инде бер 20 еллап сөйлиләрдер. Минемчә, ул моңарчы торган икән, аннан соң да шунда булсын. Экскурсиягә килүчеләр, авылдан баручылар күреп китәр. Мин дә Мәскәүгә баргач, карап чыккан идем. 1974 ел иде ул. Халыкның очы-кырые юк. Чират торып керергә туры килде. Бик матур итеп ята иде ул. Бер кешегә дә авырлык килми бит, ятсын шунда тынычлап.

Безнең Русия түрәләре һәр мәрхүм җитәкчене хурлап бара. Ә шулай да СССР вакытында тәртиптә яшәдек. Комсомоллар шәһәрләр төзеде бит! Хәзер гөрләп торган Яр Чаллы, Алабуга, Түбән Кама – алар тырышлыгы нәтиҗәсе. Колхоз рәисләре юньле-башлы йорт та салып чыга алмады. Чөнки анда халык контроле, райком, исполком бар иде. Шуңа күрә, урлау дигән нәрсә булмады. Аннан СССРны таркаттылар, Горбачев килгәч, үзгәртеп кору башланды. Аны Ельцин дәвам итте. Дөньяның асты өскә килде. Җитмәсә, хәзер бу ике җитәкчене үтереп мактыйлар. Кем өчендер бу үзгәрешләр яхшы булды. Миллионнарны кесәләренә салып куйдылар бит. Балаларына, оныкларына да җитәрлек итеп.

Әй, мактана идек 5-6 млн. икмәк уңышы алдык, дип. Минә үткән җәй күрмәгәнне күрсәтте. Быел тирә-күршене баетып, аларның чүп-чарын сатып алырга мәҗбүр булдык. Ипекәй уңса, түрәләр мактана, юк булгач, Аллаһы Тәгалә гаепле икән.

Ә коррупциядә гаепле түрәләрнең уң кулларының бармакларын кисәсе иде. «Без булдырабыз», – дип кенә әйтү аз – ныклы законнар чыгарырга кирәк. Әгәр Ленин бабай юлы белән барган булсак, коммунизмга чыгар идек, ә хәзер киредән байлар белән хәерчеләр барлыкка килде. Кая барабыз хәзер – билгесез?! Шуңа да яшәве бик куркыныч…

**Мөҗәһидан МОРТАЗИН. Мөслим районы, Исәнсеф авылы. «БГ», 10 август, 2011, №31.**

# «БУЛГАРИЯ» үзе белән Татарстан круиз туризмын да батырды

«Булгария» корабы батканнан соң, Татарстанда туристлык лайнерларга юлламалар азайган гына түгел, кешеләр елга сәяхәтенә бөтенләй чыкмас булганнар диярлек. Фаҗигагә кадәр сәяхәт билетлары алдан ук сатылып бетә торган булса, хәзер исә көненә 1 яисә 2 билет кына сатыла. Алай гына да түгел, алдан алып куйган сәяхәт билетларын кире тапшыралар.

Круиз туризмының «Булгария» корабы кебек төпкә китеп баруын туктату максатыннан, Татарстан яшьләр эшләре, спорт һәм туристлык министрлыгы, «Идел сәяхәте» ширкәте белән бергәләп, матбугат җыены уздырды.

Чарада әйтелгән мәгълүматларга караганда, Идел – 180, Чулман елгасы исә 370 километрга кадәр Татарстан территориясе буйлап сузыла. Әлеге елгалар буенча килгән чит төбәк туристлары башкалабыз Казанда туктала, Болгар һәм Зөя кебек тарихи урыннары барып күрә ала.

2008 елда Казан елга порты – 1006, 2009да – 839 һәм узган ел 894 турист көймәсен кабул иткән. Әмма берсе белән дә бүгенгә кадәр берниндидә фаҗига дә булмаган. Дөресрәге, Иделдә баткан кораб вакыйгасы якын тарих битләрендә күренми: 1980нче елларда Сембердә бер кораб күпер астына кереп, өске палубасын җимергән булган.

10 июль көнне баткан корабның Иделнең Татарстан өлешендә һәм исеменең дә «Булгария» булып, борынгы Болгар шәһәреннән кайткан вакытта фаҗигагә очравы республика круиз туризмына балта белән чабу кебек булган. Моның өстенә, федераль телеканалларның бу хактагы хәбәрләрне сәгать-минуты белән җиткереп торуы, хальтка кораб сәяхәтләренә карата бер куркy барлыкка китергән.

Әмма шунысы мөһим: баткан «Булгария» корабының чын хуҗасы әле һаман да иректә. Дөрес, тикшерү эше дәвам итә… Тик менә ак этнең бәласе кара эткә, дигәндәй, «Булгария» фаҗигасеннән соң Татарстан елга туризмы исеменә төшкән тапны кем бетерер икән? Матбугат очрашуында әнә шундыйрак эчтәлектә борчулы чыгышлар яңгырады.

**Райнур ШАКИР. «БГ», 10 август, 2011, №31. (Кыскартып бирелде).**

# НИШЛӘП ХАЛЫККА САН ЮК?

Заманында антлар биреп бер партиягә кергән кешеләр үзләренә файдалырак булган икенче партиягә кереп чумдылар. Халыкны алдап рәхәт яшәүчеләр күбәйде, алар бер-беренә терәк булып, халыктан «сакланып», үзләрен кайгыртa торган законнар эшләп, типтереп яши бирәләр. Илдәге эчкечелек, наркомания, җинаятьчелек үсү аларны әллә ни борчымый. Илдәге уртача хезмәт хакы турында күңел болгаткыч саннар китерәләр. Миллиардерлар саны белән без рекорд куйдык, халык байлыгы әнә шулар кулына шуышып бетте.

Гаделлек өчен көрәшүчеләрне төрлечә кысалар. Фәүзия Бәйрәмова моңа бик ачык мисал булып тора. Халык өчен җан атып торган батыр милләттәшебезгә җинаятьче ярлыгы таксыннар әле! Нишләп әле олы урыннар биләгән Минтимер Шәймиев кебек ир-егетләребез милләтебезнең асыл затларын яклап чыкмыйлар? Тарихның гадел бәясе бүгенге көн белән генә бетми бит ул.

Татарстанда түрәләр элеваторлардагы 53 мең тонна ашлыкны да урлый ала, тыюлыктагы пошиларны да аулый, саный китсәң, алар өчен аерым закон микәнни диярсең?!

Безнең Азнакайда яшьләргә эш табуы бик авыр. Бу нидән шулай соң? Минемчә, без сайлаган депутатлар әллә нинди яңа законнар чыгарып, эш урыннарын юк итәләр, оешмалар ябыла. Ликвидация, банкротлык, оптимизация һ.б. шундый халыкка аңлаешсыз сәясәт алып барыла. Азнакайда нефтьчеләрнең бораулау эшләре идарәсе карамагында кечкенә заводны хәтерләткән БПО (база производственного обслуживания) оешмасы бар иде. Ул ябылды, көчennән килгәннәр 60-70 чакрым ераклыкка китеп, эшкә йөри башлады. Берничә ел элек район башлыгы итеп нефть тармагында эшләп танылган кешене куйганнар иде, югыйсә.

Хәзерге медицина хезмәте күрсәтү тәртипләре дә халыкка уңай түгел. Быел апрель аенда төнге вакытта миңа «Ашыгыч ярдәм» машинасы чакырырга туры килде, кан басымым күтәрелгән иде. Өйдә калдыра алмыйбыз, диеп, мине үзләре белән алып киттеләр һәм хастаханәдә калдырдылар. Ашыгыч ярдәм күрсәтүләре өчен күңелем булды. Әмма кизү торучы табиб Джанзаков миңа көндез сәгать 11дә килерсең, дип киңәш бирде дә күздән югалды. Мин хәлсез килеш иртәнге 8гә кадәр кабул итү бүлмәсендә эш сәгатьләре башланганны көтеп утырдым. Аннан мине кардиология бүлегенә урнаштырдылар. 9 көн яттым, дәваландым дисәң, арттыру булыр. Пенсионерларны дәваласаң, илнең байлыгы кими дип куркалар микән әллә?

**Фәндәс ГӘРӘЕВ, хезмәт ветераны. Азнакай шәһәре. «БГ», 3 август, 2011, №30.**

# ТАМАШАДАН КҮЗЛӘР КАМАША...

Хәзер телепрограммада ниләр бар микән дип, газета битен дә актарасы килми. Күп кешедән ишеткәнем бар, ил яңалыкларын гына карарга тырышалар. Әлбәттә, илдә ниләр булу миңа кагылмый, төрле маҗаралы сериаллар булса, шул җиткән, дип яшәүчеләр дә шактый. Андагы үтереш-суешны карарга күнеккән кешеләргә берзаман кыен булыр әле. Чөнки иртәме-соңмы ул мәхшәрне бер тыярлар, юньле депутатлар сайлауга ирешсәк, бер заман телеэфирдан тозсыз әйбер күрсәтүне бетерерләр, дип өметләнік. Күпме яшь буынны рухи гарип итеп үстердек бит инде?!

Сирәк-мирәк булса да, телевизорның «ТНВ» каналыннан рәхәтләнеп карарлык тапшырулар булгалый. Апрельнең башында шундый истә калырлык тапшыруларның берсе «Адәм белән Һава» булды. Русиянең атказанган артисты Ислямия Мәхмүтова белән Татарстанның халык артисты Хәлил Мәхмүтовларга багышланган иде ул. Хәзерге техниканың мөмкинлекләренә куанып, интерактив цифрлы телевидение ярдәмендә әлеге тапшыруны кат-кат карадык. Мәхмүтовларны күпме карасаң да, туйдырмый бит алар. Сан артыннан куып, соңгы вакытта кайбер тапшырулар алай ук сыйфатлы түгелләр.

«Яшәсен театр» тапшыруларын калдырмый карап барырга тырышам. Программада тапшыруның кемгә багышланган булуы язылмаган булу шәп түгел, әлбәттә. 8 апрельдәгесе Русиянең һәм Татарстанның халык артисты Мөнирә Булатовага багышланган иде. Тапшыру искиткеч яхшы булды. Мөнирә ханымга 19 майда 97 яшь тулды. 31 майда мәшһүр җырчы безнең арабыздан китте. Хушлашу 1 июньдә С. Сәйдәшев исемендәге зур концерт залында үтте, мин дә катнаштым. Татарстанның халык артисты Руслан Дәминов белән профессиональ музыкага игътибар җитенкерәмәве хакында фикер алыштык. Халык бик күп җыелган иде, шулай булмый ни, бөек җырчыбыз М. Булатова белән милләтебез һәрчак горурланып яшәде. Аның язмаларын тыңлап карасаң, бүгенге «йолдызлар» җырлавы һәвәскәр башкару кебек кенә ишетелә. Митинг башланганчы «Җырга һәм хыялга ышанам» дигән 23 җыр язылган аудиокассеталар һәм Мөнирә Булатова турында язылган газеталар өләштеләр.

Узган гасырның 60-70нче елларында ул бөтен Советлар Союзына билгеле җырчыга әверелә. Аңа татар операсын иң югары дәрәҗәгә күтәрешү бәхете элгә. Ул вакыттагы җитәкчеләр татар операсының Булатовалардан соң «банкротка» чыгасын күз алдына китермиләр, күрәсең. Куйган хезмәтләре, Ходай биргән таланты өчен җырчыга СССРның халык артисты, Социалистик Хезмәт Герое исемнәрен бирерлек булган. Һәрхәлдә, җырчы Ташкент, Алма-Ата, Баку кебек шәһәрләрдә хезмәт иткән булса, андый дәрәҗәләргә ирешкән дә булыр иде. Ә бездә аның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе дә юк. Бу турыдагы мәсьәләне быел республикабызның биш газетасында күтәреп карадым, әмма республика җитәкчеләре моны күрмәмешкә салышты.

Мине тагын бер нәрсә сагаита. Билгеле булганча, 14-21 март көннәрендә Казанда Мәҗит Гафури исемендәге Хезмәт Кызыл байрагы орденлы Башкорт дәүләт академия драма театры гастрольләре зур уңыш белән узды. Башкалада яшәмәсәм дә, өч спектакльне махсус рәвештә барып карадым. «Минем гаиләм» кебек күздән яшь бөртекләре тәгәрәтеп төшерә торган спектакльне күптән күргәнем юк иде. «Шәүрәкәй» белән «Хыялый» спектакльләрен дә ярятып карадык. Соңгысы масштабы ягыннан Туймазы, яки Әлмәт дәүләт драма театрлары сәхнәләре өчен кулайрак сыман. Спектакльләрдә яшьләрнең оста уйнавы сокландыра. Алар безнең Галиәсгар Камал исемендәге академия театрында «Яшь йөрәкләр» спектаклен уйнагандагы кебек, пәрдәне ачкач та ярты сәгать буена эчтәлексез шайтан туе ясап йөрмиләр. Әмма башкорт артистларының һәр спектакль ахырында магнитофон тасмасына яздырып, диктор укуында рольләрне кемнәр башкаруын әйтеп чыкмавы, үзен акламады. Артистларның «исем-фамилиясез» китеп барулары бер дә ошамады, тамашачы бик яратып аягүрә алкышлаган иде үзләрен.

Төрки халыкларның X Халыкара театр фестивалендә М. Гафури театры коллективы ике спектакль күрсәтте. Берсе – «Шәүрәкәй», икенчесе – кече залда уйналган «Кызык бу тормыш» – В. Шукшин әсәреннән тәрҗемә спектаклен мин дә карадым. Бик әйбәт уйнадылар. Башкортстанның халык артисты Тәнзилә Хисамованың ана рольләре һәрчак уңышлы була. Язгы гастрольләрдә чакта да «Минем гаиләм» спектаклендә СССРның халык артисты Гөлли Мөбарәкова белән икесен бик яратып калган идем.

Минә шул башкорт спектакльләре турында татар матбугаты бик саран язды. Гастрольләр ахырында 20 март көнне ТНВ телеканалы «Мәдәният дөньясында» тапшыруын әллә күрше тугандаш республика артистлары белән таныштыру да, саубуллашу да итеп оештырырлар микән, диеп көткән идем, булмады. Гастрольләрдән соң да спектакльләрен телевизордан күрсәтмиләр диярлек. Татарстан белән Башкортстан арасында дуслыкны ныгытырга, дип сүз куешканнар иде яңа президентлар. Әллә чын күңелдән әйтелгән сүзләр булмады микән соң ул? Уфадан «Юлдаш» радиосы, безне чит илләрдә дә тыңлыйлар, дип сөйләп торса да, аның тавышы Татарстанның Башкортстан белән чиктәш районнарында гына ишетелә. Нигә без башкорт телетапшыруларын карый алмыйбыз? Ике тугандаш халык, берберен күрергә тилмергән Сак белән Сок шикелле яшәргә тиешмени инде?

**Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ, Россия журналистлар союзы члены, хезмәт ветераны. «БГ», 22 июнь, 2011, №24.**

«Татарстан коммунисты» («Коммунист Татарстана»)
Баш редактор – Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ
Техник редактор – Дмитрий ДЕНИСОВ
Телефон: 9600623230, факс: (85592) 7-56-46
Электрон адрес: ursai55@rambler.ru,
www.kprf.ru («Коммунисты и российское общество»)

Газетаның учредителе: КПРФның Татарстан региональ бүлеге.
Учредитель һәм редакциянең адресы: 420012, а/я 3, Казан шәһәре,
Маяковский урамы, 18/39, офис 10. Тел./факс: (843) 236-28-05, 238-00-38
Газета Элемтә, информацион технологияләр һәм күмәк коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республика идарәсендә
ПИ №ТУ 16-00314 таныклыгы белән 19.02.2010 елда теркәлде.
Басарга кул кую вакыты: график буенча – 22.08.2011 ел, 10.00, кул куелды – 10.00.

«Бөгелмә типографиясе» ААҖ
423230, РТ, Бөгелмә шәһәре,
Карл Маркс урамы, 32
Телефон: (85594) 4-85-49
Заказ 44. Тираж 15000.
Бәясе ирекле.